**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«30» март 2021 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пункты гражданнары җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү торак пунктында 2020 елның 24 ноябрендә кабул ителгән 5 номерлы элек расланган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылында халык җыенының 24.11.2020 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 1000 сум күләмендә җыелган үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелергә мөмкин булган эшләр исемлеген түбәндәгечә бәян итәргә:

- халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу (янгын гидрантларын ремонтлау һәм чистарту), Кизләү авылында (алга таба анда янгын сүндерү машинасын тоту максаты белән) гараж өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;
- Кизләү авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар сатып алу (эшләр, хезмәтләр).

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Ә.Заһертдинова

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Заһертдинова